РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов
урам, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru


---

РЕШЕНИЕ
18.02.2022

КАРАР
№ 6

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының
2013 ел 03 октябрь 34 нче номерлы карары
белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә
урнашкан зиратларны карап тоту тәртибе турындагы
нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы прокуратурасының 16.02.2002 ел, №02-08-02-/118-2022 протесты нигезендә, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2013 ел 03 октябрь 34 нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районыШәмәрдән авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны карап тоту тәртибе турындагы нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктны 1.2 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.2. җирләү урыннары булып, этик, санитар һәм экологик таләпләр нигезендә, аларда үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) күмү өчен корыла торган җир участоклары, үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) яндырганнан соң мәетләрне (җәсәдләрне) күмү өчен кайгы диварлары, үлгән кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) утка бирү өчен крематорийлар, шулай ук мәетләрне (җәсәдләрне) җирләү өчен билгеләнгән башка биналар һәм корылмалар тора. Җирләү урыннары мәдәни-тарихи әһәмияткә ия булган объектларга карый ала”.

1.2. нигезләмәнең 1.5 пунктында “булырга мөмкин” сүзен “булу” сүзе белән алыштырырга.

1.3. нигезләмәләрнең 1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.6. җәмәгать зиратлары җирле үзидарә органнары карамагында. Җәмәгать зиратларының эшчәнлеге тәртибе җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә. Авыл җирлекләре территорияләрендә җәмәгать зиратларының эшчәнлеге гражданнар тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырылырга мөмкин. Дин тотучы зиратлар бер диндә мәрхүмнәрне җирләү өчен билгеләнгән. Дин тотучы зиратлар җирле үзидарә органнары карамагында булырга мөмкин. Дин тотучы зиратларның эшчәнлек тәртибе, тиешле дини берләшмәләр белән килешеп, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә. Авыл җирлекләре территорияләрендә дин тотучы зиратларның эшчәнлеге гражданнар тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырылырга мөмкин”.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев